Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР

13 март, 2026 № 5

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдәүч авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2025 елның 07 ноябрендәге 2 номерлы Сәрдәүч торак пунктындагы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Сәрдәүч торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Оштырма-Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

2026 елның 20 мартында 18 сәгать 00 минутка «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдәүч авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 07 ноябрендәге 2 номерлы Кукмара муниципаль районы Сәрдәүч торак пунктындагы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында гражданнар җыенын билгеләргә. Гражданнар җыенын Сәрдәүч авылы, Чишмәле урамы, 20 нче йорт адресындагы торак йорт янында үткәрергә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдәүч авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 07 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев